# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**
**Баулы муниципаль районы Томбарлы авыл җирлегенең Татар Томбарлы авылында**

**26 ноябрь 2025 г.** **№1**

"Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә Баулы муниципаль районы Томбарлы авыл җирлегенең Татар Томбарлы авылында гражданнар җыены

**карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Томбарлы авыл җирлегенең Татар Томбарлы авылы территориясендә теркәлгән һәм яшәү урыны буенча яшәүче балигъ булган һәр кешедән, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган яки контракт буенча хәрби хезмәткә кергән яки ирекле хезмәт турында контракт төзегән Россия Федерациясе гражданнары гаиләләреннән тыш, 2026 елда үзара салымны 350 сум күләмендә кертергә.Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә (СВОда катнашучыларга), көндезге бүлектә укучы студентларга, Томбарлы авыл җирлеге территориясендә теркәлгән, әмма теркәлү урынында өч елдан артык яшәмәгән затларга, тыл ветераннарына, I һәм II төркем инвалидларга йөкләнгән бурычларны үтәүдә ярдәм итү.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татар Томбарлы авылында юлларны карап тоту (карны чистарту, үләнне чаптыру, шул исәптән трактор тоту; Гагарин урамындагы ОПГС һәм Совет урамы белән Ленин урамын тоташтыручы ике тыкрыкны түшәү).

3. Әлеге карарны Баулы муниципаль районының Томбарлы авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып халыкка җиткерергә, Баулы муниципаль районы сайтында бастырып чыгарырга (http://bavly.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче _______________ А.М. Миназова